**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

2021 елның «05» феврале 31 №

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында ихтыярлылык үсеше» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР ИТӘ:

1.«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында ихтыярлылык үсеше» муниципаль программасын расларга

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
________________ _____№
карарына1 нче кушымта

# «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында ихтыярлылык үсеше» муниципаль программасы

Базарлы Матак авылы

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында ихтыярлылык үсеше» муниципаль программасы |
| **Программаның муниципаль заказчысы** | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны эшләүче** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге |
| **Программаның төп башкаручылары** | - Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе;<br>- Әлки районы мәдәният бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге;<br>- ТР Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасы;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе;<br>- учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр. |
| **Программа максаты:** | Әлки муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, яшүсмерләр-яшьләр арасында психоактив матдәләр куллану һәм хокук бозуларны профилактикалау, балаларны һәм яшьләрне социаль әһәмияткә ия эшчәнлектә риясыз катнашуга җәлеп итү өлкәсендә ихтыярлылык хәрәкәтен булдыру һәм үстерү өчен шартлар тудыру. |
| **Программа бурычлары** | - сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм яшьләрнең конкуренциягә сәләтен арттыру өчен уртак эшчәнлек;<br><br>- яшьләрне ихтыярый хәрәкәткә тарту;<br><br>- ирекле ресурслар белән идарә итү, ихтыярый хәрәкәтне системалы үстерү буенча кадрлар (белгечләр) әзерләү;<br><br>- оештыру рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларга, ихтыярый инициативаларга ярдәм итү буенча эшне нәтиҗәлерәк гамәлгә ашыруда ярдәм итү;<br><br>- халыкның төрле катламнарының ихтыярый эшчәнлектә катнашу белән кызыксынуны стимуллаштыру һәм ихтыярый (ирекле) булырга теләүче кешеләргә ярдәм итү;<br><br>- ихтыярый юнәлеш буенча эш тәҗрибәсе туплау һәм |

| | |
|---|---|
| | тарату;<br><br>- ихтыярый хәрәкәтне үстерүдә яңа технологияләр кертү;<br><br>-төрле социаль әһәмиятле проектлар, акцияләр, чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;<br><br>- социаль партнерлыкның төрле формаларын тормышка ашыруны тәэмин итү;<br><br>-ихтыярлылык хәрәкәтен пропагандалау (реклама агитацияләре, акцияләр үткәрү, ММЧда иреклелек темасын яктырту, SMM (социаль медиа));<br><br>- җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, мәгариф, социаль яклау системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗади һәм дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген үстерү. |
| **Программаны гамәлгә ашыру срогы** | 2021-2023 еллар |
| **Финанслау чыганагы** | - җирле бюджет |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | - ел саен ихтыярлылык эшчәнлегенә кимендә 100 кешене, шул исәптән укучы, студентлар, эшләүче һәм эшсез яшьләрне җәлеп итү;<br>- Әлки муниципаль районында актив гражданлык позициясе һәм яшьләрдә җаваплылык формалаштыруга ярдәм итүче гражданлык җәмгыяте элементы буларак ихтыярлылык хәрәкәтенең тотрыклы һәм планлы үсеше өчен шартлар тудыру;<br>- яшьләр арасында ихтыярлылык образын уңай кабул итү;<br>- ихтыярлылыкка ярдәм күрсәтү буенча бердәм тотрыклы иҗтимагый-дәүләт системасын булдыру;<br>- иҗтимагый файдалы өлкәдә иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеккә иреклелек нигезендә җәлеп итү юлы белән яшьләрне активлаштыру. |
| **Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту** | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты |

## I. ПРОГРАММАНЫ ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПРОБЛЕМА ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Ихтыярлылык – социаль партнерлыкның һәм гражданлык җәмгыяте үсешенең уникаль ресурсы. Ихтыярлылык җәмгыять тормышының социаль-әһәмиятле мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт, территорияләрне төзекләндерү һәм үстерү, өлкән яшьтәге кешеләргә һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, балаларга, социаль яктан якланмаган гражданнарның башка категорияләренә ярдәм итү өлкәләрендәге проблемаларны хәл иткәндә иҗтимагый-дәүләт көчләрен берләштерү өчен нигез булып тора.

Соңгы елларда ихтыярый ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү дәүләт сәясәтен формалаштыруда яңа мөһим этап булды, бу турыда Владимир Владимирович Путинның 2017 елның 27 ноябрендә яңа бәйрәм – Россия ихтыярлылар көнен (волонтер) гамәлгә кую турында 572 номерлы Әмергә кул куюы да дәлилли. Шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 6 декабрендәге 583 номерлы Әмере белән Россия Федерациясендә 2018 ел Ихтыярлылар (волонтер) елы дип игълан ителде.

Әлки муниципаль районында ихтыярый хәрәкәтне үстерүгә аерым игътибар иреклелек яшьләрдә сәламәт яшәү рәвеше һәм көндәшлеккә сәләтлелек формалаштыру өчен җәмгыять таләбе нигезендә социаль әһәмиятле программаларны гамәлгә ашыруда актив катнашу исәбенә гражданлык позициясен формалаштыруның мөһим инструментларының берсе булып торуы белән бәйле.

2020 елда Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге базасында Башкарма комитет җитәкчесе карары белән Әлки муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, яшүсмерләр-яшьләр арасында психоактив матдәләр куллану һәм хокук бозуларны профилактикалау, балаларны һәм яшьләрне социаль әһәмияткә ия эшчәнлектә риясыз катнашуга җәлеп итү өлкәсендә ихтыярый хәрәкәтне формалаштыру һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатыннан, Әлки муниципаль районының Ихтыярлылык үсеше координация үзәге оештырылды.

Яшьләр ихтыярлыгы (ireклелеге), шулай ук аларның белемнәрен һәм тормыш күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү, социальләштерү, яшьләрнең үз-үзләрен реализацияләү һәм актуальләштерү буенча нәтиҗәле алымы буларак мөһим фактор булып тора.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның төп максаты булып Әлки муниципаль районында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, яшүсмерләр-яшьләр арасында психоактив матдәләр куллану һәм хокук бозуларны профилактикалау, балаларны һәм яшьләрне социаль әһәмияткә ия эшчәнлектә риясыз катнашуга җәлеп итү өлкәсендә ихтыярый хәрәкәт булдыру һәм үстерү өчен шартлар тудыру тора.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм яшьләрнең конкуренциягә сәләтен арттыру өчен уртак эшчәнлек;
- яшьләрне ихтыярый хәрәкәткә тарту;
- ирекле ресурслар белән идарә итү, ихтыярый хәрәкәтне системалы үстерү буенча кадрлар (белгечләр) әзерләү;
- оештыру рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларга, ихтыярый инициативаларга ярдәм итү буенча эшне нәтиҗәлерәк гамәлгә ашыруда ярдәм итү;
- халыкның төрле катламнарының ихтыярый эшчәнлектә катнашу белән кызыксынуны стимуллаштыру һәм ихтыярый (ирекле) булырга теләүче кешеләргә ярдәм итү;
- ихтыярый юнәлеш буенча эш тәҗрибәсе туплау һәм тарату;
- ихтыярый хәрәкәтне үстерүдә яңа технологияләр кертү;
-төрле социаль әһәмиятле проектлар, акцияләр, чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;

- социаль партнерлыкның төрле формаларын тормышка ашыруны тәэмин итү;

- ихтыярый хәрәкәтне пропагандалау (реклама агитацияләре, акцияләр үткәрү, ММЧда иреклелек темасын яктырту, SMM һ.б.).

- җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, мәгариф, социаль яклау системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗади һәм дини оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген үстерү.

## III. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Программа чаралары исемлеге 1 һәм 2 нче кушымталарда китерелгән.

## IV. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны тормышка ашыру механизмнары булып тора:

- уку йортлары базасында, шул исәптән гамәлләргә өйрәтү программаларын куллануны да кертеп, ихтыярый берләшмәләрнең актив үсеше;

-электрон һәм басма массакүләм мәгълүмат чараларын, социаль челтәрләрне һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, яшьләр арасында ихтыярый эшчәнлекне популярлаштыру;

- ихтыярлылык инфраструктурасын үстерү һәм мониторинглау, шул исәптән халыкны ихтыярый эшчәнлеккә җәлеп итүче ихтыярый оешмалар булдыру һәм үстерү;

- ихтыярый хезмәтне бүләкләү системасын камилләштерү;

- оешмалар, белгечләр һәм ихтыярлылар арасында алган белемнәрен һәм тәҗрибәсен тапшыру, шул исәптән төбәкара, Бөтенроссия һәм халыкара чараларда, проектларда, программаларда катнашуны да кертеп, системасын камилләштерү.

Программаның төп башкаручылары: Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлеге, Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, Әлки муниципаль районы

Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге, Әлки муниципаль районының финанс – бюджет палатасы, Әлки муниципаль районының Ихтыярлылык үсеше координация үзәге, учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр.

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты үз вәкаләтләре чикләрендә ихтыярлылыкны үстерү процессы белән җитәкчелек итә.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ

Әлеге Программаны тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

- ел саен 100 дән дә ким булмаган кешене, шул исәптән укучы, студент, эшләүче һәм эшсез яшьләрне ихтыярый эшчәнлеккә җәлеп итү;

- Әлки муниципаль районында яшьләр ихтыярый хәрәкәтенең тотрыклы һәм планлы үсеше өчен гражданлык җәмгыяте элементы буларак, яшьләр арасында актив гражданлык позициясе һәм җаваплылык формалаштыруга ярдәм итә торган шартлар тудыру;

- яшьләрдә ихтыярый яшәү рәвешен формалаштыру;

- ихтыярлылыкка ярдәм күрсәтү буенча тулы бер иҗтимагый-муниципаль система формалаштыру;

-ихтыярлылык нигезендә иҗтимагый файдалы өлкәдә иҗтимагый һәм һөнәри эшкә җәлеп итү юлы белән яшьләрне активлаштырырга;

Әлеге программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп индикаторлары булып тора:

сан күрсәткечләре:

-яшьләрнең гомуми санына карата ихтыярлылык эшчәнлегендә катнашучы яшьләр саны, процент;

Әлки муниципаль районында ихтыярый берләшмәләр һәм оешмалар саны;

- хупланган ихтыярый инициативалар саны.

сыйфат күрсәткечләре:

- район яшьләренең иҗтимагый активлыгы дәрәҗәсен күтәрү һәм аның хәзерге җәмгыять проблемаларын хәл итүгә җәлеп ителүен арттыру.

ихтыярлылар хезмәт күрсәтә торган өлкәләр:

- балалар, яшьләр, башка яшьтәге кешеләрнең ялын оештыру;

- "риск" төркеме яшүсмерләре белән социаль эш;

-мәдәни-массакүләм чаралар, акцияләр оештыру һәм үткәрү;

- мөмкинлекләре чикләнгән балалар, өлкәннәр белән эшләү;

- социаль патронатта торучы гаиләләргә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына адреслы ярдәм;

- хәйрия, гуманитар ярдәм;

- яшүсмерләр-яшьләр арасында хокук бозуларны һәм психоактив матдәләрне куллануны профилактикалау;

- яшүсмерләр-яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру;

җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә;

- территорияләр, мемориаллар, каберлекләр, ишегалды территорияләрен, парклар, скверлар һәм башкаларны төзекләндерү;

## VI. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Программаны финанслау җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

1 нче кушымта

**«2021-2023 ЕЛЛАРГА ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ИХТЫЯРЛЫЛЫК ҮСЕШЕ »**

**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ**

| № | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар | Финанслау күләме (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| **I. Белем бирү җыеннарын оештыру һәм үткәрү** | | | | | | |
| 1. | Әлки муниципаль районы ихтыярлылар форумы | Апрель, ноябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИУКҮ, ТР ӘМР МИ | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 2. | Ихтыярый оешма җитәкчеләренең муниципаль киңәшмәләре-семинарлары | Март, октябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИУКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 3. | Республика ихтыярый мәктәпләр һәм форумнары | Февраль, март, июль, сентябрь, октябрь, декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИУКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| **II. «Җиңү волонтерлары» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәте чараларын тормышка ашыру** | | | | | | |
| **Проектларны тормышка ашыру** | | | | | | |
| 1. | «Җиңү йөзе» проекты | Гыйнвар-декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИУКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җиңү волонтерлары» | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 2. | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарының интервьюлары видеоархивын системалаштыру | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИУКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 3. | Ветераннарны социаль яклау | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җиңү волонтерлары» | | | |
| 4. | Мәктәпләрдә «Җиңү дәресләре»н оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 5. | «Буыннар эстафетасы» пилот проектын тормышка ашыру | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 6. | Дан аллеяларын, истәлекле урыннарны һәм хәрби каберлекләрне төзекләндерү | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җиңү волонтерлары» | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 7. | «ЭКОдәресләр» Бөтенроссия акциясе | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җиңү волонтерлары» | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 8. | Беренче бөтендөнья сугышына багышланган интернет-квест | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 9. | Россия тарихына багышланган бөтенроссия фильмнарын карау | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 10. | «РИСК» интеллектуаль уеннар лигасы (акыл, интуиция, тизлек, команда) | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 11. | «Ватаным табигате» бөтенроссия акциясе-конкурсы | Июнь-октябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 12. | «Җиңү» бөтенроссия ЭКОгонка проекты проектын тормышка ашыру | Октябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Яшьләр өчен тарихи квестлар оештыру һәм үткәрү** | | | | | | |
| 1. | «1941. Заполярье» | 23 февраль | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 2. | Космонавтика көненә | 12 апрель | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 3. | «1942. Партизан сукмаклары» | 3 июнь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 4. | «1943. Барысы да фронт өчен» | 22 июль | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 5. | «Курск дугасы» | 27 август | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 6. | «1944. Җиңү балалары» | 9 сентябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 7. | «Севастополь өчен көрәш» | 27 октябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 8. | «1945. Җиңү» | 4 ноябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 9. | «Мәскәү өчен көрәш» | 5 декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| **«Бердәм гамәл көннәре» Бөтенроссия акцияләрен үткәрү** | | | | | | |
| 1. | «Җиңү хаты» Бөтенроссия акциясе | старт 28 гыйнварда | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Георгий тасмасы «Бөтенроссия акциясе» | старт 22 апрельдә | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | 4,0 | 4,0 | 4,0 |
| 3. | «Җиңү агачы» Бөтенроссия акциясе | старт 23 апрельдә | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 4. | «Обелиск!» Бөтенроссия акциясе | 1 Май-9 май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 5. | «Үлемсез полк» Бөтенроссия акциясе | 9 май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 6. | «Җиңү көне» Бөтенроссия флешмобы | 9 май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 7. | «Без-Россия гражданнары!» Бөтенроссия акциясе | 12 июнь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 8. | «Хәтер шәме» Бөтенроссия акциясе | 22 июнь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ «Җиңү волонтерлары» | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 9. | «Билгесез солдат көне» Бөтенроссия акциясе | 3 декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| 10. | «Ватан Геройлары көне» Бөтенроссия акциясе | 9 декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Җиңү волонтерлары» | - | - | - |
| **«Татарстанда бердәм гамәл көннәре» республика акцияләрен оештыру һәм үткәрү** | | | | | | |
| 1. | Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең туган көненә | 15 февраль | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | багышланган акция | | ТР ӘМР БК МБ «Җинү волонтерлары» | | | |
| 2. | «Ветеранның хәлен бел» акциясе | 23 февраль | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җинү волонтерлары» | - | - | - |
| 3. | «Хатын-кызлар көне» акциясе | 8 Март | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җинү волонтерлары» | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 4. | «Татарстан Икенче бөтендөнья сугышы елларында» акциясе | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җинү волонтерлары» | - | - | - |
| 5. | Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә адреслы ярдәм | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ, «Җинү волонтерлары» | - | - | - |
| **III.Республика проектларын тормышка ашыру** | | | | | | |
| 1. | «Сәламәтлек сессиясе» төбәкара проекты | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 2. | «Дөньяның бар төсләре» | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ТР ӘМР БК МБ | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 3. | Язгы игелек атнасы | 12-19 март | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Әлки РҮХ» ДАССУ, | 2,0 | 2,0 | 2,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ӘМРда ТР ХХЭТИҺСЯМ СЯИ, ӘМР БК МБ | | | |
| 4. | Көзге игелек атнасы | Сентябрь | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Әлки РҮХ» ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИҺСЯМ СЯИ, ӘМР БК МБ | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| **IV. Муниципаль проектларны һәм конкурсларны гамәлгә ашыру** | | | | | | |
| 1. | «Дуслык» | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, «Әлки РҮХ» ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИҺСЯМ СЯИ | - | - | - |
| 2. | «Ихтыярлылар- бу без» | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 3. | «#SPORTДрайвАлькеево» | Сентябрь-декабрь | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | 2,0 | 2,0 | 2,0 |
| 4. | «Төсле карандашлар» | Март-август | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 5. | #КоррупциЯпротив | Сентябрь-декабрь | ӘМР Башкарма комитеты,ТР ӘМР БК ЯСҺСБ, ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 6. | «Ел ихтыярлысы» бәйгесе | Ноябрь-декабрь | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, ӘМРда ТР ХХЭТИҺСЯМ СЯИ | - | - | - |
| 7. | «Коррупциясез территория» бәйгесе | Ноябрь | ӘМР Башкарма комитеты, ТР ӘМР БК ЯСҺСБ, ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 8. | Бөтенроссия ирекleләр көнен | 5 декабрь | ТР ӘМР БК ЯСҺСБ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бәйрәм итүгә багышланган гала-концерт һәм елга йомгак ясау | | ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, МЙ | | | |
| **V. Хәйрия акцияләре үткәрү** | | | | | | |
| 1. | «Балага Яңа ел бүләк ит» акциясе | Декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, "Әлки РҮХ" ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| 2. | Балаларны яклау көненә багышланган «Балаларга ярдәм ит» акциясе | Июнь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, "Әлки РҮХ" ДАССУ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| 3. | Өлкәннәр ункөнлеге | Октябрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| 4. | Инвалидлар ункөнлеге | Декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, "Әлки РҮХ" ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| 5. | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар, социаль патронатта торучы балалар, өлкәннәр һәм ветераннар өчен яңа ел тамашалары | Декабрь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, "Әлки РҮХ" ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| 6. | Социаль патронатта торучы гаиләләргә адреслы ярдәм | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, "Әлки РҮХ" ДАССУ, ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар | бюджеттан тыш акчалар |
| **VI. Шәһәр профилактик акцияләре** | | | | | | |
| 1. | Укучылар һәм студентлар өчен интерактив дәресләр | Ел дәвамында | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе | - | - | - |
| 2. | «Тизрәк, югарырак, акыллырак» | Июнь-август | ТР ӘМР БК ЯСhСБ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт-уен квесты. | | ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе | | | |
| 3. | «ГТО мәйданчыгы» сәламәтлек фестивале | Май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе, МЙ | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 4. | «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен! Кушылыгыз!» акциясе | Февраль | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 5. | «Яшь буын сәламәт киләчәк өчен» акциясе | Март | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | - | - | - |
| 6. | «Ирекле тормыш» акциясе | Апрель | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе | - | - | - |
| 7. | СПИДтан үлгәннәрне искә алу көнен үткәрү кысаларында «Хәтерлә мине» акциясе | Май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе, «Әлки РҮХ» ДАССУ | - | - | - |
| 8. | «Яшьләр тәмәкегә каршы. Мәңгегә!»Бөтендөнья тәмәкесез көн кысаларындагы чаралар | Май | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 9. | «Тормыш бер генә тапкыр бирелә» акциясе | Июнь | ТР ӘМР БК ЯСhСБ ИҮКҮ, ТР ӘМР МИ, Россия ЭЭМ Әлки районы буенча бүлекчәсе | - | - | - |
| **Барлыгы:** | | | | **30,0** | **30,0** | **30,0** |
| Шул исәптән муниципаль бюджеттан: | | | | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Шул исәптән республика бюджетыннан: | - | - | - |
| **Программа буенча барлыгы:** | **90,0** | | |

**ӘМР** - Әлки муниципаль районы

**ТР ӘМР БК ЯСhСБ** - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге

**ӘМРда ТР ХХЭТИhСЯМ СЯИ** - Әлки муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе

**ТР ӘМР МИ** - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе

**ТР ӘМР БК МБ** - Әлки районы мәдәният бүлеге

**ИҮКҮ** - Әлки муниципаль районы Ихтыярлылык үсеше координация үзәге

**«Җиңү волонтерлары»** - «Җиңү волонтерлары» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлегенең Әлки бүлекчәсе

2 нче кушымта

**«2021-2023 ЕЛЛАРГА ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ИХТЫЯРЛЫЛЫК ҮСЕШЕ » МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ КЫСАЛАРЫНДА ТОРМЫШКА АШЫРЫЛА ТОРГАН ПРОЕКТЛАР ҺӘМ АКЦИЯЛӘР**

1. 1 нче декабрьдән 25 нче декабрьгә кадәр үздырыла торган «Балага Яңа ел бүләк ит!» хәйрия акциясе мөмкинлекләре чикле балалар һәм авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен хәйрия ярдәме, татлы бүләкләр җыю максаты белән үткәрелә. Акциянең нәтиҗәсе-алар өчен яңа ел бәйрәмнәре уздыру һәм адреслы ярдәм .

2.10 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр «Балаларга ярдәм ит» хәйрия акциясе авыр тормыш хәлендә булган 0-15 яшьлек балалар өчен әйберләр җыю, социаль патронатта торучы гаиләләр өчен азык - төлек, әйберләр җыю максаты белән үткәрелә.

3. #SPORTАлькеевоДРАЙВ - «Сәламәтлек сессиясе» төбәкара проекты кысаларында актив ял итү эшчәнлегенә җәлеп итү юлы белән Әлки муниципаль районы студентларының, шул исәптән «риск» төркемендәге авыр тормыш хәлендә булган, ПДНда исәптә торучы, шулай ук тулай торакларда яшәүче студентларның физик һәм интеллектуаль сәламәтлеген үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән проект.

4.Быел гамәлгә ашыра башлаган коррупциягә каршы #КоррупциЯпротив проекты Үзәк яшьләрдә коррупциягә карата гражданлык позициясен формалаштыру өчен шартлар тудыра, аерым алганда: инновацион эш рәвешләрен кулланып, яшьләр өчен коррупциягә каршы чаралар оештыра һәм үткәрә. Алар арасында тренинг элементлары белән дәресләр, әңгәмәләр, мастер-классклар, конкурслар, соц.сораштыру, тест, квестлар, форумнар һәм акцияләр.